Уракчы авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 18 ноябре Уракчы ав. № 25

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында

2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Уракчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыУракчы авыл җирлегенең энергияне сак тоту һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген арттыру» муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районыУракчы авыл җирлеге башкарма комитетын программаның заказчысы – координаторы итеп билгеләргә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Урахча авылы, Совет урамы, 36а йорты; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Гәрәев